ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.10.2018 с. Верхний Услон 1207

Югары Ослан муниципаль районы
территориясендә 2018нче елның
12нче октябреннән 30нчы ноябренә кадәрге
чорда янгынга каршы махсус режим
билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2018нче елда Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында" 2018нче елның 9нчы апрелендәге 215нче номерлы Карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән профилактик чараларны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012нче елның 2нче апрелендәге 390нчы номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018нче елның 12нче октябреннән 30нчы ноябренә кадәр Югары Ослан муниципаль районы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда тыела:

- коры үләнне һәм чүп-чарны яндыру;
- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында "2014нче ел, 12нче апрель, 236нчы нчы карары белән расланган исемлеккә кергән гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерцияле булмаган берләшмәләре, икътисад объектлары, урман кишәрлекләре белән чиктәш савыктыру оешмалары территорияләрендә, урман-парк зонасында, торфлы кишәрлекләрдә һәм урман массивлары белән чиктәш ачык территорияләрдә куркыныч янаучы 1-3нче сыйныф пиротехника әйберләрен куллану;
- урман массивларында һәм аның янәшәсендәге территорияләрдә палаткалар лагерьларын төзекләндерү.

3. Авыл җирлекләре башлыкларына, Иннополис шәһәре мэрына, милек формасына бәйсез оешма, предприятие җитәкчеләренә:

- торак пунктлар чикләрендә һәм ведомство карамагындагы объектларда коры үләннән һәм чүп-чардан территорияне чистарту буенча чаралар күрергә;

- торак пунктларны һәм икътисад объектларын саклау өчен урман массивларыннан һәм коры үләннән ут чыгу куркынычы яный торган территориядә сукаланган урыннарны яңартырга;

- янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларын урнаштыру һәм төзек хәлдә тоту, буалар һәм ясалма сулыкларны оештыру, шулай ук аларга каты өслекле керү юлларын оештыру буенча эшне оештыру;

- баланста булган янгынга каршы су белән тәэмин итүнең тышкы чыганакларының эшкә сәләтлелеген тикшерү;

- янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычы булган эшләрне чикләргә;

- халык арасында янгынга каршы тематикага агитация һәм пропаганда материаллары торак-коммуналь хуҗалык, электр энергиясе, газ һ.б. хезмәтләре күрсәтү счетларында таратуны оештырырга;

- Югары Ослан янгын сүндерү-коткару гарнизоны ГПС бүлекчәләре хезмәткәрләре, «Татарстан Республикасы Янгыннан саклау» Татарстан Республикасы Дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләре, Югары Ослан муниципаль районы буенча янгын куркынычсызлыгы дәүләт учреждениесе хезмәткәрләре, Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» МБ хезмәткәрләре, Югары Ослан муниципаль районының ирекле янгын сагы әгъзалары, волонтерлар кертелгән авыл җирлекләре һәм бакча җәмгыятьләре чикләрендә профилактик төркемнәр төзергә;

- авыл җирлекләре чикләрендә җаваплылык зонасы торак секторының профилактик төркемнәре әгъзаларын беркетергә һәм алар көче белән торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре, янгынга каршы пропаганда турында халыкка хокукый белем бирү һәм хокукый мәгълүмат бирү рәвешләрендә профилактик чаралар үткәрергә;

- торак пунктларда янгын сүндерү өчен су сибү һәм башка җайлаштырылган техниканы җәлеп итүне оештырырга;

- янгын сүндерү техникасы белән ирекле янгын сагы әгъзаларының тәүлек буе кизү торуын оештыру буенча чараларны контрольдә тотарга;

- торак пунктларда, бакчачылык ширкәтләрендә һәм кооперативларда ирекле янгын дружиналарын оештырырга, аларны сумкалы янгын сүндергеч һәм янгын сүндерү өчен шанлы корал белән тәэмин итәргә.

4. Югары Ослан янгын сүндерү һәм коткару гарнизонына:

- янгыннарның үсешен һәм кешеләр үлүен стабильләштерүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар комплексын планлаштырырга һәм үткәрергә;

- янгын куркынычы булган хәлне катлауландырганда Югары Ослан янгын сүндерү-коткару гарнизонының көчен һәм чараларын югары әзерлек режимына китерергә.

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы буенча ОНД УНД һәм Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Баш идарәсенә:

- Югары Ослан муниципаль районы торак пунктларының, гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерцияле булмаган берләшмәләре территорияләренең янгынга каршы торышын тикшерү;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Янгынга каршы режим турында" 2012нче елның 25нче апрелендәге 390нчы номерлы карары белән расланган, шулай ук Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының "Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запастагы җирләрендә ачык уттан файдалану һәм учаклар ягу тәртибен раслау турында" 2016нчы елның 26нчы гыйнварындагы 26нчы номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре таләпләрен исәпкә алып, көнкүрештә гражданнарның янгын куркынычсызлыгы чаралары турында, үлән яндыру тәртибен аңлату буенча эшне оештыру һәм үткәрү ;

- гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре территорияләрендә тиешле профилактик эш оештыру һәм үткәрү;

- массакүләм мәгълүмат чараларында торак пунктларда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә проблемалы мәсьәләләрне яктырту, шулай ук халыкка янгын куркынычсызлыгы чаралары турында хәбәр итү.

6. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Югары Ослан муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә торак пунктларда һәм урман массивларында янгыннар барлыкка килүне кисәтү максаты белән :

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә камыл, коры үлән һәм чүп-чарны санкциясез яндыруны кисәтү һәм ачыклау буенча эшне оештырырга;

- ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләренә "Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запастагы җирләрендә ачык уттан файдалану һәм учак ягу тәртибен раслау турында" Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2016нчы елның 26нчы гыйнварындагы 26нчы номерлы боерыгы таләпләрен җиткерергә;

**түбәндәгеләр буенча чаралар күрү:**

- авыл хуҗалыгы оешмалары һәм фермер хуҗалыклары тарафыннан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм аның янәшәсендәге урман массивларында кыр эшләрен үткәргәндә урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру;

- кыр һәм торак пунктлар янындагы урман массивлары урыннарнын сукалау;

- авыл хуҗалыгы предприятиеләре, фермер хуҗалыклары территорияләрен коры-сарыдан чистарту;

- авыл хуҗалыгы формированиеләре балансында булган техниканы тәүлек буе янгын сүндерү һәм янгын сүндерү максатлары өчен җайлаштырылган янгын сүндерүне, шулай ук төзек булмаган янгын техникасын ремонтлауны оештыру.

7. ДКУ "Идел буе урманчылыгы"на, ДКУ "Идел буе урман хуҗалыгы"на :

- Югары Ослан муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары белән берлектә урман янгыннарын кисәтү һәм алар белән көрәшкә юнәлтелгән оештыру-техник чаралар үткәрүне тәэмин итү;

- урман массивларында һәм алар янында урнашкан табигый һәм ясалма сулыктан янгын техникасы белән су алу өчен мәйданчыкларны төзекләндерүне дәвам итү;

- урман янгыннарын башлангыч үсеш стадиясендә үз вакытында ачыклауга, локальләштерүгә һәм бетерүгә юнәлдерелгән оператив чаралар кабул итүне тәэмин итәргә;

- урман янгыннарын сүндерү өчен расланган урман янгыннарын сүндерү планнары нигезендә көч һәм акча җәлеп итәргә;

- Югары Ослан муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына торак пунктларның урман массивларына тоташкан чикләре буйлап минеральләштерелгән полосаларны төзекләндерүдә булышлык күрсәтүне оештырырга;

- урман фондында ачыкланган барлык янгын учаклары турында мәҗбүри тәртиптә Югары Ослан муниципаль районы ЕДДСка җиткерергә кирәк.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **Л.С. Хакимзянов**